**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 13 февраль № 87

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карары белән расланган Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карары белән расланган Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пункттагы «планнан тыш тикшерүләр» сүзләре алдына «планлы (рейд) караулар, тикшерүләр рәвешендә» сүзләрен өстәргә;

9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«План (рейд) буенча караулар, тикшерүләр план (рейд) йөкләмәләре нигезендә вәкаләтле органнарның вазыйфаи затлары тарафыннан аларның компетенциясе чикләрендә үткәрелә. Мондый йөкләмәләрне рәсмиләштерү тәртибе һәм аларның эчтәлеге һәм план (рейд) буенча карауларның, тикшерүләрнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе вәкаләтле органнар тарафыннан аларның компетенциясе нигезендә билгеләнә.»;

11 нче пунктның дүртенче абзацындагы «кече предприятиеләргә карата» сүзләреннән соң «- 50 сәгатьтән дә арттырмыйча» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\87.doc